**КАРАР**

**Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Наратлы Кичү авыл җирлеге составына кергән Исәнгол торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**10 ноябрь, 2019 ел.** **№ 1**

**РЕШЕНИЕ (КАРАР)**

2003 елның 6 октябрендәге "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында"гы №131-ФЗ нең 25.1, 56 маддәләре, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында"гы №45-ЗРТ Законының 35 маддәсе нигезендә 2019 елның 10 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар түбәндәге мәсьәлә буенча җыен беркетмәсе төзелде: "2020 елда Минзәлә муниципаль районы Наратлы Кичү авыл җирлегенең Исәнгол торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән (көндезге формада укучы студентлардан, БВС ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, 1 һәм 2 нче төркем инвалидлардан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән тыш) 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган чараларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә Сез ризамы?"

1. Ритуаль хезмәтләрне оештыру һәм җирләү урыннарын карап тоту:

-зиратны койма белән әйләндереп алу.

2. Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:

- ике телдә урам исемнәре һәм йорт нумерацияләре язылган алтакталар әзерләү.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 66 гражданнар җыенында катнашучы кертелгән, тавыш бирүдә катнашучы гражданнар җыенында катнашучылар саны 34 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен 34 гражданнар җыенында катнашучы тавыш бирде;

"Юк" позициясе өчен 0 җыенда катнашучы тавыш бирде.

Югарыда бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Наратлы Кичү авыл җирлегенең Исәнгол торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен – гамәлдә дип танырга.

1. "2020 елда Минзәлә муниципаль районы Наратлы Кичү авыл җирлегенең Исәнгол торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр

яшәүчедән (көндезге формада укучы студентлардан, БВС ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, 1 һәм 2 нче төркем инвалидлардан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән тыш) 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган чараларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә Сез ризамы?" мәсьәләсе буенча карарны танырга:

1. Ритуаль хезмәтләрне оештыру һәм җирләү урыннарын карап тоту:

-зиратны койма белән әйләндереп алу.

2. Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:

- ике телдә урам исемнәре һәм йорт нумерацияләре язылган алтакталар әзерләү.

2. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Наратлы Кичү авыл җирлеге Советының мәгълүмати стендларында, Минзәлә муниципаль районы сайтында: http://menzelinsk.tatarstan.ru/ Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы һәм http://pravo.tatarstan Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматенең рәсми порталы составында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.
3. Гамәлдәге карарны Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлар регистрына кертү өчен Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Наратлы Кичү авыл җирлегенә җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: ____________________ ____________________

Наратлы Кичү авыл җирлеге Башлыгы,
Совет рәисе ________________ Ф.Х.Минһаҗев.